**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**АГРАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 72-1 08.10.2019 ел.

Шәһәртөзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле
әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү өчен
аерым вәкаләтләрне кабул итү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 нче бүлеге, Татарстан Республикасы Спас муниципаль район Советының 2019 елның 7 октябрендәге 42-4номерлы“Шәһәртөзелеше эшчәнлеге өлкәсендә аерым вәкаләтләрне бирү турында” карары, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Советының 2019 елның 16 июлендәге 67-1 номерлы “Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү өчен аерым вәкаләтләрне бирү турындагы Килешүләр төзү тәртибен раслау турында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Советы КАРАРЫ:

1. Шәһәртөзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү өчен «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең аерым вәкаләтләрен кабул итәргә:

- җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертү һәм раслау;
- җир биләмәләреннән файдалану һәм җирлек төзелеше кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү һәм раслау;
- җирлекнең шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча җирле нормативларына үзгәрешләр кертү һәм раслау.

2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан кабул итү турында килешү төзүне тәэмин итәргә.

3.Әлеге карарны Аграмак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ www. spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) законда билгеләнгән срокта урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль
районы Аграмак авыл җирлеге башлыгы: Р.Т. Галәветдинова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АГРАМАКОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»
СОВЕТ АГРАМАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ